| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.06.2020 г.Казань № 464.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 14 июлендә 6759 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы "Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы "Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.02.2016 ел № 61, 11.12.2017 ел № 863, 16.07.2018 ел № 561, 12.10.2018 ел № 938, 20.05.2019 ел № 380, 14.11.2019 ел № 1024 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.А.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының
2020 елның 29 июнендәге 464
номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы "Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карары белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында - http://www.mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

дүртенче абзацта «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 729-р номерлы күрсәтмәсе» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы «Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре һәм башка оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган, эчендә дәүләт йөкләмәсе (заказ) яисә муниципаль бирем (заказ) урнашкан, дәүләт яки муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле һәм электрон рәвештә күрсәтелгән хезмәтләр исемлеген раслау турында» күрсәтмәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктының «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пункттагы «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына таләпләр аталышы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси рәвештә телдән, шул исәптән телефон аша мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш; язмача, шул исәптән электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә - мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып сигез эш көненнән. Шәхси рәвештә телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә бирелә, язмача мөрәҗәгать иткәндә гаризада күрсәтелгән ысул белән мәгълүмат хаты әзерләгәннән соң икенче көнне бирелә (җибәрелә). Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату Россия Федерациясе законнары белән каралмаган»;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктының «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «442-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2.14 пункттагы «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасында «181-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон (алга таба - 181-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә, «527н номерлы боерык» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы «Инвалидларга объектларны һәм хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне файдалану

мөмкинлеген тәэмин итү шартларын, шулай ук аларга моның өчен кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» боерыгы (алга таба – 527н номерлы боерык)» сүзләренә алмаштырырга;

2.15 пункттагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау составында күрсәтелми»;

3.3.2 пункттагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көннән гамәлгә ашырыла. Электрон гариза ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта - ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көнендә.»;

3.4.2 пунктының икенче абзацында «ике эш көне» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең һәм башка хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».